ГЛАВА МАЙДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.48, с. Майдан, 422587

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ МӘЙДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 48 нче йорт, Мәйдан авылы, 422587

Тел.: (84379) 35-0-48, факс: (84379) 35-0-48.

22.11.2024 № 2

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Мәйдан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
карар

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?: - Мәйдан авылындагы торак пункт чикләрендә җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү, дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 22 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 13 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 12 катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авылына гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2.Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегенең Мәйдан авылында 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл

итүгә юнәлтүгә ризамы?:- Мәйдан авылындагы торак пункт чикләрендә җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү, дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa.

3.Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендәге гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Михеев